РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ТЕТЮШСКИЙ ГОРОДСКОЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

тел. 8(84373) 2-51-58, motetushi@rambler.ru, e-mail: tatesh@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_14.12.2022_ № __22__

**Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында»2010 елның 22 июлендәге 880 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Тәтеш шәһәр Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Тәтеш шәһәр Башкарма комитетының 20.12.2021 ел, №19 карары «җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр башкаруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты» үз көчен югалткан дип танырга.

2. Җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр башкаруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru/ Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында (http://tetushi.tatarstan.ru/).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** **А.А. Никоноров**